Балачагымны сугыш урлады.

# Буразнада үскән балалар.




Сугыш ул- бик куркыныч нәрсә,
Кан ул, ут ул, үлем, яралар,
Күз яшьләре, ачлык, кайгы,
Тол аналар, ятим балалар.

# Сугыш…Сугыш башланган оланнар!

Сугыш…

Моннан зуррак хәвеф, зуррак афәт

Булдымы икән җирдә тагын да.

Ач балалар килә күз алдына

Шул сүз ишетелгән чагында.



Ул елларны ничек онытасың,

Ир-егетләр китте яу кырына.

Без кайтырбыз дип киткән юлдан

Китсәләр дә алар кайтмады.

Алар өчен бары җилләр генә

Ачып-ябып йөри капканы.



Хөрмәт итәм татар

хатыннарын,

Ихтирамым – олы йөрәктә.

Олы җанлы алар.

Иң нык заттан.

Андый ныклык юктыр ташта

да.



Чыдамлылар алар. Чыдадылар

Иңгә салып авыр елларны.

Язгы таңда яфрак шаулавында

Җыр ишетсәң, син дә колак сал.

Ләйсән яңгырлары яуган чакта

Тыңла,дустым,тизрәк отып кал.

Алар булыр батыр солдаткаларның

Җырланасы моңсу җырлары.



Әтиләре сугышып йөргән чакта,

Тәпи йөрер- йөрмәс бала-чага

Буразнада билчән утаган.

Илгә-ИКМӘК, авыл үзе өчен


Көлчә салган алабутадан.

Бөек Ватан сугышында

Ир-егеткә иңдәш булды,

Каһарманга тиңдәш булды,

Сылу, гүзәл хатын-кызлар.



Сугыш чоры кешеләренең

Исемнәрен ташка нык уеп,

Кулдан килсә әгәр бронзадан

Һәйкәл куяр идем мин коеп.

Килеп йөрер идем шул һәйкәлгә


Батырлыкны кабат күрергә.

Өйрәнергә тормыш авырлыгын

Алар кебек җиңә белергә.



Буразнада үскән балалар. Әтисез калган сабыйлар, карга батып урман да кискән, сукага җигелеп , җир дә сөргән, кибәнен дә куяганнар, саламын да өйгәннәр.Башыңа – кәләпүшең,өстеңә-бишмәтең,аягыңа- аяк киемең, ашарыңа туйганчы ипиең булмагач, мондый балачакны бәхетле балачак дип атап булмый, әлбәттә.




# *Мәңге сүнми торган хәтирә*

**Сугыш дигән шомлы аваз иртән**
**Бәгырьне телеп үткәндә,**
**Мин бит яшь ярымлык бала идем,**
**Син сугышка чыгып киткәндә**
**Иркәләдең алып кулларыңа,**
**Үзең никтер читкә карадың,**
**Дерелдәгән бармакларың белән**
**Чәчләремне генә тарадың.**
**Мин ябыштым синең муеныңа,**
**Ала алмас кебек беркем каерып.**
**Әткәй, китмә!-дигән кебек елап калдым,**
**Сугыш барыбер алды аерып.**



Толларның күзендә ,
Ятимнәр йөзендә
Сугышның шәүләсе бар һаман.
Күңелдә шом яши,
Җәен дә җан өши-
Сугышлар булмасмы яңадан?
Яз назлар өр-яңа гөлләрне,
Тик толлар күзеннән ,
Ятимнәр йөзеннән
Сугышның шәүләсе бетәрме?



# Сезнең тормыш- үзе батырлык.

Их апалар, абыйлар, сугыш елларында
Теңкәгезгә тиде авырлык.
Заман авырлыгын күтәрергә,
Зур кайгылар баштан үткәрергә,
Кайдан тылсымлы көч таптыгыз
Кайдан алдыгыз сез сабырлык?!
Сезнең сабырлыкка, батырлыкка
Мәңге-мәңге хәйран калырлык.



***Елап калды сабыйлар.***

**Ирләр китте, балалар елап калды. Шаулап калды иген өлгереп,**


**Басу капкасына чаклы озата барды Яше, карты- барсы өзелеп.**

**Ирләр китте, кызлар елап калды,**

**Елап калды күпме хатыннар.**

**Туйда кигән күлмәкләре калды,**

**Күпме бала калды, ятимнәр.**



# Дан җырлыйк без бу буынга.

Үтте.. Үтте...

Ир кулы түгел,

Тормыш тотты нәфис куллардан.

Дүрт баласы бергә елаганда,

Көнләштеләр кызлар толлардан.

Ишекләре ачык…

Ирләре бүген тагын кайтмады.




Бу ятимнәр соңгылары булсын.

Кеше каны бүтән акмасын

Безнең әткәйләргә төшкән бомба

Музейларда гына саклансын.



Яшик без гел шулай кояшлы,

Тыныч көннәргә сөенеп.

Һәркемнең күңелендә бер теләк:

Иминлек!

Иминлек!

Иминлек!

